Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

30 октябрь 2020 ел № 10

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 28 августындагы 389 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бирү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Ачыклау тәртибендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 28 августындагы 389 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларындаТатарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бирү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидияләр бирү максатлары һәм шартлары Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба - район башкарма комитеты) һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы җирлеге башкарма комитеты (алга таба - җирлек башкарма комитеты) арасында әлеге карар нигезендә Финанс - бюджет палатасы приказы белән расланган типовой форма нигезендә төзелә торган килешү белән билгеләнә.»;

8 пунктта «Финанс - бюджет палатасы» сүзләрен «район башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга.»;

9 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«9. Килешүгә район башкарма комитеты җитәкчесе һәм җирлек башкарма комитеты җитәкчесе кул куя.»;

15 пунктта «гамәлгә ашыралар» сүзен «гамәлгә ашыра» сүзләренә алмаштырырга, «һәм Финанс - бюджет палатасы» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник», газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 январеннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының бюджет - финанс мәсьәләләре, салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов